| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 4 декабрь № 918

г. Казань

Лизинг оешмаларына Россиядә җитештерелгән газ-мотор техникасын сатып алу максатларында алынган кредитлар һәм заемнар процентларын түләү чыгымнарының бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2013-2023 елларга Татарстан Республикасында газ-мотор ягулыгы базарын үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 26 апрель, 283 нче карары белән расланган «2013-2023 елларга Татарстан Республикасында газ-мотор ягулыгы базарын үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы чараларын тормышка ашыру һәм эшчәнлекләрен Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашыручы эшмәкәрлек эшчәнлеге субъектларына газ-мотор ягулыгында эшли торган автобуслар һәм торак-коммуналь хуҗалык техникасы сатып алуда дәүләт ярдәме күрсәтү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Лизинг оешмаларына Россиядә җитештерелгән газ-мотор техникасын сатып алу максатларында алынган кредитлар һәм заемнар процентларын түләү чыгымнарының бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен (карарга теркәлә) расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\918.docx

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 3 декабрь, 918 нче
карары белән расланды

Лизинг оешмаларына Россиядә җитештерелгән газ-мотор техникасын
сатып алу максатларында алынган кредитлар һәм заемнар процентларын түләү
чыгымнарының бер өлешен каплауга
Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү
ТӘРТИБЕ

1. Әлеге Тәртип лизинг оешмаларына Россиядә җитештерелгән газ-мотор ягулыгында эшли торган автобуслар һәм торак-коммуналь хуҗалык техникасы сатып алу (алга таба аларны лизинг шартнамәләре буенча эшчәнлекләрен Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашыручы эшмәкәрлек эшчәнлеге субъектларына – индивидуаль эшмәкәрләргә һәм (яки) юридик затларга биреп) максатларында алынган кредитлар һәм заемнар процентларын түләү чыгымнарының бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр (алга таба – субсидияләр) бирү кагыйдәләрен һәм шартларын билгели.

2. Субсидияләр билгеләнгән тәртиптә әлеге Тәртипнең 1 нче пунктында күрсәтелгән максатларга Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына (алга таба – Министрлык) күздә тотылган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә бирелә.

3. Субсидия түбәндәге шартларга җавап биргән лизинг оешмаларына бирелә:

а) лизинг оешмасы Икътисадый үсеш һәм интеграция буенча Хөкүмәт комиссиясе тарафыннан расланган система барлыкка китерүче оешмалар исемлеге нигезендә автомобиль сәнәгате буенча система барлыкка китерүче оешмалар каршында төзелгән булу (комиссия утырышының 2015 ел, 5 февраль, 1 нче беркетмәсе). Лизинг оешмасының устав капиталындагы система барлыкка китерүче предприятиенең катнашу өлеше 51 проценттан ким булмаска тиеш;

б) лизинг компаниясенең Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына мәҗбүри түләүләр буенча вакыты чыккан кредиторлык бурычлары булмау;

в) финанс арендасы (лизинг) шартнамәсе буенча, Таможня берлеге комиссиясенең 2011 ел, 9 декабрь, 877 нче карары белән расланган «Тәгәрмәчле транспорт чаралары куркынычсызлыгы турында» Таможня берлегенең техник регламентына теркәлгән 1 нче кушымтада күрсәтелгән классификация нигезендә, лизинг оешмасы Россиядә җитештерелгән M, N һәм O категорияле газ-мотор техникасын сатып ала һәм бирә.

Лизинг оешмасының субсидия күләмен исәпләү ссуда бурычының калган өлеше (түләү вакыты чыккан бурычны исәпкә алмаганда), кредиттан файдалана торган көннәр саны буенча алып барыла һәм алынган кредит яки заем буенча билгеләнгән ставкадан чыгып исәпләнгән процентлар суммасы (күп дигәндә еллык

17 процент) һәм еллык 12 процент ставкасы буенча процентлар суммасы арасындагы аерма буларак билгеләнә.

4. Субсидия бирү Министрлык һәм лизинг оешмасы арасындагы субсидия бирү турында шартнамә (алга таба – Шартнамә) нигезендә гамәлгә ашырыла.

Шартнамә формасы Министрлык тарафыннан раслана.

Шартнамәдә субсидия бирү тәртибе, аның максатчан билгеләнеше, лизинг оешмасы тарафыннан субсидияне кире кайтару очраклары һәм тәртибе, Министрлык һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан лизинг оешмасының субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвенә тикшерүләр үткәрүгә лизинг оешмасының ризалыгы күздә тотыла.

5. Шартнамә төзү өчен лизинг оешмасы Министрлыкка, түбәндәге документларны теркәп, ирекле формада Шартнамә төзү турында гариза кертә:

а) лизинг оешмасы җитәкчесе тарафыннан таныкланган әлеге лизинг оешмасын акчалар яки башка мөлкәт белән операцияләр башкара торган һәм эшчәнлек өлкәсендә күзәтчелек органнары булмаган оешма сыйфатында исәпкә кую турында Финанс мониторингы федераль хезмәтенең хәбәрнамәсе күчермәсе;

б) лизинг оешмасы җитәкчесе һәм баш бухгалтеры тарафыннан имзаланган, лизинг оешмасы мөһере белән расланган (Россия Федерациясе законнары нигезендә мөһергә ия булу күздә тотылган очракларда) Россия кредит оешмаларында ачылган хисап исәпләренең банк реквизитлары хакында белешмә, һәм әлеге исәпләргә уңай карар кабул ителгән очракта субсидия күчерелә;

в) барлык өстәмә килешүләрне, кушымталарны теркәп, финанс арендасы (лизинг) шартнамәләре, шулай ук финанс арендасы (лизинг) шартнамәсе нигезендә транспорт чараларын кабул итү-тапшыру актлары күчермәләре. Финанс арендасы (лизинг) шартнамәсе 2014 елның 1 декабреннән башлап һәм кимендә бер елга төзелергә тиеш.

г) барлык өстәмә килешүләрне, кушымталарны теркәп, кредит яки заем шартнамәләре, кредит яки заем шартнамәләре буенча түләү графиклары күчермәләре;

д) финанс арендасы (лизинг) шартнамәсе буенча бирелә торган транспорт чаралары паспортлары күчермәләре.

6. Лизинг оешмасы үз ихтыяры буенча түбәндәге документларны кертергә хокуклы:

а) салым органыннан билгеләнгән тәртиптә таныкланган лизинг оешмасының Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына мәҗбүри түләүләр буенча вакыты чыккан кредиторлык бурычлары булмауны раслый торган белешмә, аны бирү датасы Министрлыкка керткән мизгелдән 30 көннән дә иртәрәк булмаска тиеш;

б) юридик затны дәүләт теркәвенә алу турында шаһәдатнамә күчермәсе;

в) Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә.

7. Лизинг оешмасы бу Тәртипнең 7 нче пунктында күрсәтелгән докуменларны тапшырмаган очракта, Министрлык әлеге документларны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала.

8. Министрлык:

а) кертелгән документларны ике көн эчендә беркетелгән, бит саннары куелган һәм Министрлык мөһере белән расланган булырга тиешле махсус журналда терки;

б) документларны теркәгән көннән соң өч эш көне эчендә аларда булган мәгълүматларның тулылыгын һәм дөреслеген тикшерә, Шартнамә төзү турында яки аны төзүдән баш тарту хакында карар кабул итә һәм лизинг оешмасына кабул ителгән карар турында хәбәр итә.

9. Шартнамә төзүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

а) лизинг оешмасының бу Тәртипнең 3 нче пунктында күрсәтелгән шартларга туры килмәве;

б) лизинг оешмасы тапшырган документларның әлеге Тәртипнең 6 нчы пункты таләпләренә туры килмәве яки документларда тулы булмаган һәм дөреслеккә туры килмәгән мәгълүматлар булуы.

10. Шартнамә төзү турында карар кабул ителгән очракта, Министрлык әлеге карарны кабул иткән көннән биш эш көне эчендә лизинг оешмасы белән Шартнамә төзи.

11. Субсидия алу өчен, Шартнамә төзегән лизинг оешмасы ай саен, хисап аеннан соң килә торган айның 30 ына кадәр, түбәндәгеләрне теркәп, Министрлыкка ирекле формада субсидия күчерү турында гариза кертә:

а) әлеге Тәртипкә теркәлгән кушымтада бирелгән форма нигезендә субсидия күләмен исәпләү;

б) Россиядә җитештерелгән газ-мотор техникасын сатып алу максатларында алынган кредитлар һәм заемнар буенча процентларны фактта түләүне раслый торган түләү йөкләмәләре күчермәләре.

12. Министрлыкка әлеге Тәртипнең 12 нче пункты нигезендә кертелгән документлар, Министрлыкка кертелгән көннән соң ике эш көне эчендә, беркетелгән, бит саннары куелган һәм Министрлык мөһере белән расланган булырга тиешле махсус журналда теркәлә.

13. Министрлык теркәгәннән соң ике эш көне эчендә бу Тәртипнең 12 нче пункты нигезендә лизинг оешмасы тарафыннан кертелгән документларда булган мәгълүматларның тулылыгын һәм дөреслеген тикшерә һәм тикшерү нәтиҗәләре буенча субсидия күчерү турында яки субсидия күчерүдән баш тарту хакында карар кабул итә.

14. Министрлык түбәндәге очракларда субсидия күчерүдән баш тарта:

а) әлеге Тәртипнең 12 нче пункты нигезендә лизинг оешмасы тарафыннан кертелгән документларда булган мәгълүматларның тиешенчә тутырылмавы, тулы һәм дөрес булмавы;

б) документларда булган мәгълүматларның бу Тәртип таләпләренә туры килмәве.

15. Субсидия күчерүдән баш тарту хакында карар кабул ителгән очракта, Министрлык әлеге карарны кабул иткән көннән соң биш эш көне эчендә лизинг оешмасына, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, документларын кире кайтара.

16. Субсидия күчерү турында карар кабул ителгән очракта, Министрлык әлеге карарны кабул иткән көннән соң биш эш көне эчендә субсидияне кредит оешмасында ачылган лизинг оешмасының хисап исәбенә күчерә.

17. Субсидия түбәндәге очракларда, Министрлыкның тиешле таләбен алганнан соң, эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә лизинг оешмасы тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш:

а) субсидия алу өчен дөреслеккә туры килмәгән мәгълүматлар һәм документлар тапшыру;

б) субсидия акчасыннан максатка ярашсыз файдалану;

в) кредитлар һәм заемнар буенча процентларны түләмәү;

г) төзелгән шартнамәләр нигезендә кредит яки заемны үз вакытында түләмәү.

18. Хисап финанс елында файдаланылмаган субсидияләр лизинг оешмасы тарафыннан Татарстан Республикасы бюджеты керемenә хисап аеннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр кире кайтарылырга тиеш.

19. Лизинг оешмасы әлеге Тәртипнең 18 нче һәм 19 нчы пунктларында билгеләнгән субсидияне кайтару вакытларын бозган очракта, Министрлык әлеге вакытлар чыккан көннән эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә әлеге акчаны Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән тәртиптә чаралар күрә.

20. Министрлык һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы лизинг оешмасының субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвен тикшерүне законнар нигезендә гамәлгә ашыра.

21. Субсидиядән максатчан һәм нәтиҗәле файдалануны тикшерүдә тоту законнар нигезендә Министрлык тарафыннан гамәлгә ашырыла.

F:\KARAR\2015\918_1.docx

Лизинг оешмаларына Россиядә җитештерелгән газ-мотор техникасын сатып алу максатларында алынган кредитлар һәм заемнар процентларын түләү чыгымнарының бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә кушымта

Форма

______________________________________________________________ өчен
(хисап чоры, бер айга кабул ителә)

**лизинг оешмаларына Россиядә җитештерелгән газ-мотор техникасын сатып алу максатларында алынган кредитлар һәм заемнар процентларын түләү чыгымнарының бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия күләмен**

**ИСӘПЛӘҮ**

______________________________________________________________________________
(оешманың тулы исеме)

ИНН____________________, КПП _________________, хисап исәбе ________________ , _____________________________________________,
(кредит/заем биргән оешма исеме)

БИК _____________________, корреспондент исәбе ______________________, ОКВЭД буенча оешманың эшчәнлек төре коды_______________________.

| Лизинг шартнамәсе реквизитлары, лизинг алучы | Еллык 12 процент ставкасы буенча процентлар суммасы, сум | Кредит яки заем бирү шартнамәсе реквизитлары | Алынган кредит яки заем буенча билгеләнгән ставкадан чыгып исәпләнгән процентлар суммасы (әмма күп дигәндә еллык 17 процент), сум | Хисап чоры ахырына кредит яки заем бирү шартнамәсе буенча калган бурыч | Субсидия күләме (6=4-2), сум |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| | | | | | |
| Барлыгы | | | | | |

Субсидия күләме ____________________________ сум (6 графадан барлык сумма)

Оешма җитәкчесе _____________________ _________________________
(имзасы) (Ф.И.Ат.и.)

Баш бухгалтер _____________________ _________________________
(имзасы) (Ф.И.Ат.и.)

«__» __________ 20__ ел. М.У.